**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2016 елның 18 апреле** **№42**

«Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләре турында» 2007 елның 27 июнендәге 127 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Су кодексы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уставы нигезендә, Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2007 елның 27 июнендәге 127 номерлы карары белән расланган шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. статьяда 2 пунктны түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктчасы белән өстәргә:

«2.6. гомуми кулланылыштагы су объектларында судан файдалануны чикләү турында халыкка мәгълүмат бирү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет»челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының Экология, аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Кама-Тамагы муниципаль районы

башлыгы урынбасары,

Кама Тамагы муниципаль районы

Советы Рәисе урынбасары Г. А. Габидуллин